**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «2021–2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүнең төп юнәлешләре турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «2021–2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүнең төп юнәлешләре турында» 2021 елның 21 маендагы ПУ-398 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 28 июлендәге 519 номерлы һәм 2024 елның 9 мартындагы 183 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасында «2021–2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 пунктта:

беренче абзацта «2021–2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

«а» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт хезмәтенә керергә теләк белдергән махсус хәрби операция ветераннарының һәм анда катнашучыларның һөнәри компетенцияләрен үстерү;»;

«д» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ясалма фәһем чараларын кулланышка кертү;»;

в) 3 пунктта «2021–2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 28 гыйнвар
№ 64